# «Иртәнге комплимент”
# “Утренний комплимент”



# Тема:
# Иярчен кире җөмләләр.

# Фонетик зарядка.

# Өй эшен тикшерү

Бу китапны саклагыз, югыйсә ул башка укучыларга калмас.
Син безнең белән сөйләшергә теләмисең, алайса без дә синең белән аралашмыйбыз.
Мин кайтырмын, шул вакытта син сөйләрсең.
Сез киңәш биргәннән соң, ул бик үзгәрде.
Әгәр мин бу китапны укып чыксам, аннары син дә укырсың.

# ИЯРЧЕН КИРЕ ҖӨМЛӘ

## Синтетик төре

| Бәйләүче чара | Мисаллар |
| --- | --- |
| 1. Шарт фигыль формасы: -са/ -сә + да, дә кисәкчәсе | Өе тар булса да, күңеле киң Җаббарның. (Ә. *Фәйзи)* |
| 2. Хәл фигыль формасы: *–кач/* -гәч, -кач /-кәч + та, тә кисәкчәсе | Мәктәп балаларына ял булгач та, әнкәй белән әткәйгә бу кагылмый. *(Н. Әхмәдиев)* |
| 3. Ияртүче теркәгеч: гәрчә + -са/ -сә шарт фигыль формасы + да, дә кисәкчәсе | Гәрчә Баязит абый эчкерсез киңәшчем, риясыз остазым булса да, мин аны да оныттым. *(А. Гыйләҗев)* |
| 4. Бәйлек сүз: карамастан | Дәртле музыка уйнап торуга карамастан, күңелгә кереп оялаган ямансулык хисе кичерәйми дә, таралмый да. (*М. Маликова)* |

# ИЯРЧЕН КИРЕ ҖӨМЛӘ

**Иярчен кире җөмлә я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән кире хәлне ачыклый, я баш җөмләнең кире хәле урынында килә.**

## Аналитик төре

| Бәйләүче чара | Мисаллар |
|---|---|
| Ялгызак мөнәсәбәтле сүз: **шулай да, алай да, шулай булса да, шуңа карамастан** | Бу хәл Маһруй апаны бик җәберсетте, шулай да ул зарланып йөрмәде. (Г. *Әпсәләмов)*<br>Кызны танымады Госман, алай да йөрәк тирәсендә нидер сулкылдап алды. (И. *Салахов)*<br>Вәзир Исхакны шәех Игәнәй яратмады, шуңа карамастан ул аны хөрмәт итте. *(М. Хәбибуллин)* |

## Җөмләләргә анализ ясарга.

1. Көннәр яхшырырга охшаган, шулай булса без чаңгы шуарга чыгар идек. ( ), [шулай булса]
2. Телебезне сакларга кирәк, югыйсә ул югалырга мөмкин. ( ), [югыйсә]
3. Тырышып укымыйсың икән, чиреккә яхшы билгеләр чыкмый. (икән), [ ]
4. Илең турында уйласаң, гомереӊ озын була. (...саң), [ ]
5. Ул китте исә, Нәсимә көнләшә. (исә), [ ]

**Бер якта – җөмләләр, икенче якта шул җөмләләрнең схемалары бирелгән. Дөрес җавапны табып язарга кирәк.**

| | |
|---|---|
| **1. Мине сөйсәң, онытуганыңны** | **. (...-сам да), [ ]** |
| **2. Егылсам да, антым хәтеремдә һәркайчан.** | **(...-са да), [ ]** |
| **3. Яратмаса, кыен түгел, төзәтү бу хатаны** | **(...-саң), [ ]** |
| **4. Безне язмыш аерса да, дуслыкны, бәгърем, онытма.** | **(...-сак та...), [ ] .** |
| **5. Кайтмасак та яныгызга, сез безнең йөрәкләрдә** | **(...-са), [ ]** |

**Җавап: 1-3, 2-1, 3-5, 4-2, 5-4**

# Дәрес тәмам!

Кәефләрегез
ничек?
Сәламәт
булыгыз

